**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралу сәбәпле, имин булмаган вазгыять шартларында кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралуны булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралуны булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән профилактика, диагностика, дәвалау, чикләү һәм башка чараларны гамәлгә ашыру, карантин һәм башка чикләүләрне кертү һәм бетерү ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 24 августындагы 588 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралу сәбәпле имин булмаган вазгыять шартларында кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) эпизоотия чыганакларында:

«Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы авылындагы Ленин урамы 55 А номерлы йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә;

«Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы авылындагы Ленин урамы 73 номерлы йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә;

б) «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы авылы территориясе чикләрендә урнашкан имин булмаган пунктта;

в) имин булмаган пункт чикләреннән кимендә 10 километр радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Сарман районының Түбән Чыршылы авылын, Язикәү авылын, Ләке авылын, Ферма Сәүекле поселогын, Петровский Завод авылын, Дуслык авылын, Пробуждение авылын, Мостафа авылын, Чукмарлы авылын, Юлтимер авылын, Шыгай авылын, Усай авылын,

Янурыс авылын, Наратасты авылын, Димитарлау авылын, Азалак авылын, Олы Нөркәй авылын, Күктау авылын, Зәй районының Зичәбаш авылын, Кабан Бастырык авылын, Дүртмунча авылын, Тукай районының Таулык авылын, Яңа Бүләк авылын, Күктәк-Мирсәет авылын, Иске Теләнче авылын, Кызыл Байрак авылын, Бай Бүләк авылын, Иске Дөреш авылын кертеп, куркыныч янаган зонада.

2. Әлеге Указның 1 пункты «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән территорияләрдә бер ел дәвамында түбәндәгеләрне тыярга:

йогышлы төерле дерматит авыруына каршы вакцина ясалмаган терлекләрне транспортта кертүне;

авыруга бирешүчән терлекләрне имин булмаган пункт территориясеннән транспортта чыгаруны (авыруга бирешүчән терлекләрне чалу өчен терлек чалу предприятиеләренә яисә шушы максатларда җиһазланган терлек чалу пунктларына транспортта чыгарудан тыш);

авыруга бирешүчән терлекләрне туплау белән бәйле ярминкәләр, күргәзмәләр, сәүдә итүләр һәм башка чаралар үткәрүне.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралу сәбәпле, имин булмаган вазгыять шартларында чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 25 гыйнварындагы ПУ-55 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 02 март
№ ПУ-181